ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**15 нче ноябрь, 2021 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№12-10**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 21 июлендәге 16-04 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 01 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы
**КАРАР ИТТЕ:**

**1.** Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 21 июлендә кабул ителгән 16-04 санлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына (үзг.белән 27.04.2018 ел, № 28-04; 16.09.2019 №40-03; 09.11.2019 №41-08; 26.02.2020 №45-03; 12.08.2020 №47-05; 11.09.2020 №48-03; 02.11.2020 №02-07) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның 7 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен үзләренә беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;»

1.2. 8 статьяның 10 пунктындагы 6 абзацында «Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3. 10 статьяның 9 пунктындагы 3 пунктчасына «бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.4. 8 статьяның 10 пунктындагы 2 пунктчасына «бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

**2.** Әлеге карарны Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында (www.Aktanysh.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга.

**3.** Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

**4.** Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитетына йөкләргә.

Актаныш муниципаль районы Советы Рәисе Э.Н.Фәттахов